КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 сентябрь г.Казань № 953

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы; 2020 ел, 4 ноябрь, 994 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2022 ел, 16 июнь, 569 нчы; 2022 ел, 18 август, 853 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:


«Аңлатма язуы» бүлегендә:

ундүртенче абзацта «464,802» саннарын «464,706» саннарына алмаштырырга;

«Югары Ослан муниципаль районы» бүлегендә:

Югары Ослан муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары Ослан муниципаль районы




[25] – Река Свияга
[51] – Печищинский геологический разрез
[52] – Каменный овраг
[53] – Овраг Черемушки
[54] – Река Сулица
[55] – Озеро Озеро
[56] – Зоостанция КГУ – массив Дачный
[57] – Горный сосняк
[58] – Кликовский склон
[59] – Свияжский
[185] – Ташевские склоны
[186] – Кураловские родники
[187] – Стратиграфический разрез казанского и уржумского ярусов у поселка Кзыл-Байрак
[193] – Лесной ключ
[206] – Волжские просторы»;


«Клыковский сөзәклеге [58]» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Клыковский сөзәклеге [58]»;

«Свияжск [59]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Свияжск [59]

| | |
|---|---|
| Статус | Комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге - дәүләт табигать тыюлыгы |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1998 ел, 4 февраль, 49 нчы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 гыйнвар, 1 нче карары |
| Урнашу урыны | Югары Ослан һәм Зеленодольск муниципаль районнары |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |



Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Тыюлыкның гомуми мәйданы 12 552,56 гектар тәшкил итә.

Тыюлыкны оештыру Свияга елгасының, Куйбышев сусаклагычындагы Свияжск култыгының һәм аның янындагы тугайларның табигый һәм ясалма экосистемаларын, балыкларның кәсеп һәм сирәк төрләре запасларын, уникаль табигый ландшафтын һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу зарурлыгына нигезләнгән. Су һәм су янындагы экосистемаларны тикшерү 1916 елдан бирде алып барыла. Хайваннарның һәм үсемлекләрнең биологик төрлелеге һәм популяцияләренең югары продуктивлыгы территориянең табигатьне саклау статусы югары булу белән аңлатыла.

Территория флорасында күп тамырлы үсемлекләрнең 500 дән артык төре бар. Зоопланктон һәм зообентос составында 120 гә якын төр билгеләнә. Ихтиофаунаның – 48 төре, герпетофаунаның – 16ы, орнитофаунаның – 120е, териофаунаның 42 төре исәпләнә.

Әлеге территория үсемлекләрнең һәм хайваннарның (шул исәптән Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрнең) бик күп төрләре яшәү урыны булып тора (үсемлекләр: тармаклы наратбаш, йөзгәләк сальвиния, ап-ак төнбоек, дару песи борчагы; хайваннар: тупалакбаш, түбәнавыз, соры гөберле бака, тарак сыртлы тритон, бакыр кәлтә, кара елан, зур күлбуга, ысылдавык аккош, балыкчы карчыга, кыр һәм дала чалкошлары, бөркет, ак койрыклы диңгез бөркете, дала лачыны, соры торна, яңгыр чыпчыгы, саескан шөлди, үлән шөлдие, зур чуаркош, зур саз шөлдие, зур шөлди, кечкенә акчарлак, колаклы һәм сазлык ябалаклары, йорт чырайсыз ябалагы, һөдһөд, күк карга, алтын корташар, гади яр чыпчыгы, ак песнәк).

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы нигезендә.»;

«Кызыл Байрак поселогы янындагы Казан һәм Уржум катламнарының стратиграфик уемы [187]» бүлекчәсендә:

бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


татар текстында үзгәрешсез кала;

өченче абзацта татар текстында «Казан һәм Уржум» сүзләре үзгәрешсез кала;

«Зеленодоль муниципаль районы» бүлегендә:

Зеленодоль муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы




[25] – Река Свияга
[59] – Свияжский
[76а] – Волжско-Камский государственный природный биосферный заповедник (Раифский участок)
[76в] – Охранная зона Раифского участка Волжско-Камского государственного природного биосферного заповедника
[78] – Озеро Бело-Безводное
[79] – Озеро Провальное
[81] – Озеро Собакино
[82] – Колония серой цапли
[83] – Ильинская балка
[84] – Овражно-балочная система «Никольская»
[85] – Овражно-балочная система «Фахри Яры»
[86] – Овражно-балочная система «Кишангер»
[203] – Шорский
[205] – Озеро Черное
[206] – Волжские просторы»;

«Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгындагы Раифа участогының саклау зонасы» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгындагы Раифа участогының саклау зонасы [76в]».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә төбәк әһәмиятендәге «Лесной ключ» дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгын оештыру турында» 2013 ел, 4 май, 300 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 21 май, 382 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче; 2019 ел, 27 март, 226 нчы; 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче; 2022 ел, 22 февраль, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге «Лесной ключ» дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча Комитетның функцияләре

6. Комитет, тыюлык бурычларын үтәү максатларында, түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

хайваннар дөньясы объектларын саклау, яңадан үрчетү белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын файдалануны җайга салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшләве өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару;

махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (табигать дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау санитариясе) саклавын тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген кертеп).»;

III һәм IV бүлекләр үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин